КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 775

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалану тәртибе турында» 2016 ел, 22 август, 581 нче карары белән расланган Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәт бирү тәртибе хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалану тәртибе турында» 2016 ел, 22 август, 581 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 1 апрель, 257 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затлар атамаларында Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәт бирү тәртибе хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлары кертелгән юридик затка, шулай ук гариза һәм әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән документлар кергән көнгә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлары кертелмәгән оешманы гамәлгә куючыга (гамәлгә куючыларга) карата

вәкаләтле орган ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында билгеләнгән вакыт эчендә Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу (булмау) турында мәгълүматлар соратып ала.».

5 пунктта «биш көн эчендә» сүзләрен «10 көн эчендә» сүзләренә алыштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Вәкаләтле орган тарафыннан рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләрне үтәмәү;

гариза һәм әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән документлар кергән көнгә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлары кертелмәгән юридик затның, оешманы гамәлгә куючының (гамәлгә куючыларның) Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин